ГЛАВА
КУТЛУ-БУКАШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422665, с.Кутлу-Букаш.
ул.Советская , дом 32

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
КОТЛЫ БӨКӘШ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
422665, Котлы Бөкәш авылы
Совет урамы, 32 йорт

Тел.: (84361) 31521, факс: (84361) 31642, e-mail: Kbuk.Rs@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2019 елның 22 октябрендә Котлы Бөкәш авылы № 1

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Котлы Бөкәш авыл җирлегенең Котлы Бөкәш, Тәберде Чаллысы, Мәмле Казаклар Чаллысы, Сатлыган авыл торак пунктларында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июлендәге "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 45-ЗРТ номерлы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы "Котлы Бөкәш авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставының 22 маддәсе нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Котлы Бөкәш авыл җирлегенең Сатлыган авылы торак пунктында үзара салым кертү буенча гражданнар җыенын 2020 елның 02 ноябрендә 10 сәг. 00 минутка билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Котлы Бөкәш авыл җирлегенең Мәмле Казаклар Чаллысы авыл торак пунктында үзара салым кертү буенча гражданнар җыенын 2020 елның 03 ноябрендә 10 сәг. 00 минутка билгеләргә

3. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Котлы Бөкәш авыл җирлегенең Тәберде Чаллысы авыл торак пунктында үзара салым кертү буенча гражданнар җыенын 2020 елның 10 ноябрендә 10 сәг. 00 минутка билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Котлы Бөкәш авыл җирлегенең Котлы Бөкәш авыл торак пунктында үзара салым кертү буенча гражданнар җыенының беренче этабын 2020 елның 12 ноябрендә 10 сәг. 00 минутка билгеләргә.

5. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Котлы Бөкәш авыл җирлегенең Котлы Бөкәш авыл торак пунктында үзара салым кертү буенча гражданнар җыенының икенче этабын 2020 елның 12 ноябрендә 14 сәг. 00 минутка билгеләргә.

6. Гражданнар җыенын үткәрү өчен торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген бүлү территориаль билге буенча гамәлгә ашырылуын расларга.

7. Гражданнар җыены каравына куела торган сорауны расларга:

Сез 2021 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Котлы Бөкәш авыл җирлегенең Котлы Бөкәш, Тәберде Чаллысы, Мәмле Казаклар Чаллысы, Сатлыган авылы торак пунктларында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән, көндезге формада белем алучы студентлардан , тумыштан инвалид булган, 1 группа инвалид, баласыз япа-ялгыз яшәүче яшьләре 80 нән узган өлкән яшьтәге кешеләрдән кала һәм аларның гомуми саны җирлектә яшәүчеләрнең 30% тан артмаган очракта, 400 сум күләмендә үзара салым акчасы кертүгә һәм тупланган средстволарны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга ризамы:

- кышкы юлларны кардан чистарту;
- Котлы Бөкәш авыл җирлегендәге авыл урамнарына вак таш җәю;
- вак таш тигезләү өчен трактор хезмәтләренә түләү;
- урам утларының яктырту системасына хезмәт күрсәтү;
- Котлы Бөкәш һәм Тәберде Чаллысы авылларында балалар мәйданчыгы сатып алып урнаштыру;
- “Сабантуй” уздырыла торган мәйданны койма белән тотып алу;
- Тәберде Чаллысы зираты коймасын тоту.

“ЯКЛЫЙМ” “КАРШЫ”

6. Әлеге карарны дәүләт теркәвеннән соң өч көн эчендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Котлы Бөкәш авыл җирлегенең түбәндәге адрес буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында урнаштырырга: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Котлы Бөкәш авылы, Совет урамы, 32 йорт; Тәберде Чаллысы авылы, Совет урамы, 34 йорт; Мәмли Казак Чаллысы авылы, Үзәк урам, 29 йорт һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда.

7. Карар басылып чыккан  (халыкка белдерелгән) көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль  районы
Котлы Бөкәш авыл җирлеге башлыгы                    Г.Г. Нәҗипов